

Педагог һәм остаз елында Ботен-россия педагогик династияләрен барлыйлар. Нәселле педагоглар, гаиләләрендә буыннан-буынга тапшырыла торган тәжрибә турында проектлар тозеп, конкурсларда катнашалар. Үткән ел узган утырышларнын берсендә Россия мәгариф министры Сергей Кравцов болай дигән иде: «Кайбер гаиләләрдә буыннан-буынга укытучы хезмәтенә мәхәббәт һәм хормәт бирелә - бу уникаль педагогик династияләр, алар ботен ил буенча 500 дән артык. Мондый гаиләләрнен тарихлары һәркемгә билгеле булырга, vсеп килvче буын, булачак педагоглар очен vрнәк булырга тиеш».      Шулай, укучыларга мәхәббәт белән караган, ижади якын килеп хезмәт иткән Надия Хосәен кызы (Сюняева-Кильдеева) белән Шакир улы Рәстәм Кильдеев педогоглар династиясе вәкилләре гаиләсенен дәвамчысы, бvген Саранск шәһәре “Республиканский лицей”да тырышып укучыларга чит телләр буенча белем бирvче Рәстәм кызы Наилә Ларина мен елдан арткан династия турындагы проект эше белән Ботенроссия конкурсында катнаша. Сезгә бу династия турында горурланып ишеттерергә телибез.

- Нәсел агачы - шәжәрәне барлаганда, зур горурлык хисләре кичердек. Гомерләрен могаллимлек эшенә багышлаган, бездә дә бу эшкә мәхәббәт уяткан әби-бабаларыбызнын, абый-апаларыбызнын тормыш юллары бездә соклану һәм кызыксыну уятты. Дистә еллар буена эстафета булып кvчә барган әлеге һонәргә безнен гаиләнен мәхәббәте әле дә сvнми, сvрелми. Һәм без vзебезнен нәкъ менә шушы олугъ, хормәтле, затлы нәселдән булуыбыз белән чын кvнелдән горурланабыз. Чыннан да, бар нәрсәнен башлангычы - Укытучы кулында. Укытучыга да, атаклы галимгә дә, тозvчегә дә беле



мне Укытучы бирә. Кешелек барында бу һонәр яшәячәк, - ди әнгәмәдәшем Наилә Рәстәм кызы. - Безнен укытучылар династиясенен чишмә башы XIX гасырга барып тоташа. Укытучы һонәрен сайлаучы кvнел юмартлыгына, эчке байлыкка



ия булырга, vз эшен бирелеп башкаручы булырга тиеш. Гомерләрен балаларга белем һәм тәрбия бирvгә багышлаган Кильдеевлар-Тумпаровлар укытучылар династиясенен гомуми эш станы 739 ел, ә әнием ягы Сюняевлар гаиләсенен - 485 ел. Барлык туганнарым кан буенча гына тvгел, ә олы йорәкле, эш соючәнлелеге, югары әхлак сыйфатлары белән дә туганнар.

Сvземне бабамнын әтисе Алимбек Кильдеевтан башларга телим. Ул Кадошкино районы Большие Поляны авылында акыллы, белемле һәм зур хөрмәткә ия кеше булган. Якташларын мәдрәсәдә гарәп теленә ойрәткән. Алимбек улы Шакирга, минем бабакаема, хормәт йозеннән “Ага” дип кушамат биргәннәр, чонки ана яше-карты кинәш белән килгән. Ә бабаемнын оч улы да озак еллар директор вазыйфасын vтәгәннәр: Равиль Шакир улы (Почетная грамота РМ) – 6 ел Инсар медучилище директоры, әтием Рәстәм Шакир улы (Почетный работник просвещения РФ) - 28 ел авылыбыз Большие Поляны мәктәбе директоры иде, Рашид Шакир улы (Почетная грамота РМ) – Краснослободск зоо-ветеринар техникумынын 30 ел директоры булган. Гаиләмнен урам кушаматы да - “директорлар”. Мәсәлән, “директор хатыны” әнием Надия Хосәен кызы, “директор кызы” мин - Наилә Рәстәм кызы... Әйе, әйтvе генә жайлы директор кызы, дип. Директор кызы булу бик авыр иде ул. Һәрвакыт яхшы укырга кирәк, тәртибен дә vрнәк булырга тиеш. Ин беренче булып укытучы кушканнарны да син vтәргә тиеш, беркайчан да сvз тынламыйча утыра алмыйсын. Әтием белән әнием мине шундый булырга ойрәтте.
Һонәри осталыклары, хезмәтенә бирелгәнлекләре, балаларны яратулары, тыйнаклыклары нәтижәсендә алар хезмәттәшләренен һәм ата-аналарнын, балаларнын хормәтен казандылар. Гаиләм династиясенен кvбесе олы бvләкләр ияләре. Муся улы Мохәммәтжан Кильдеев белән Мирза кызы Әйшә Кильдееванын, Татарстаннын Балтач районы Сосна мәктәбе укытучыларынын фидакарь педагогик хезмәтләре



Ленин ордены белән бvләклән. Мәгариф эшендә тынгысыз хезмәте очен, Мордовиянен Кадошкино районы Большие Поляны урта мәктәбе укытучысы, директоры Роза Али кызы Тумпарова Мордовиянен атказанган укытучысы исеменә лаек; Адилә Хасян кызы Сюняева - Узбекистаннын атказанган укытучысы, Эльвира Әхмәтжан кызы Усманова - Татарстаннын атказанган укытучысы. Минем бабаем Алимбек улы Шакир - Россиянен почетлы хезмәткәре, әнием Надия Хосәен кызы – Россия мәгариф отличнигы...
Лев Николаевич Толстой әйткәнчә: “Әгәр укытучы эшен генә яратса - ул яхшы укытучы булачак.
Әгәр укытучынын әтисе, әнисе кебек укучыга мәхәббәте генә булса, ул барлык китапларны укыган, әмма эшне дә, укучыларны да яратмаган укытучыдан яхшырак булачак. Әгәр дә укытучы vзендә эшкә һәм укучыларга мәхәббәтне берләштерә икән, ул - камил укытучы...” Камил укытучылар династиясе вәкиле мин. Киләчәктә укытучылар династиясе дәвам ителер дип уйлыйм. Гаиләдә балалар да әти-әниләренен эшен кvреп, укытучы хезмәтенә хормәт белән vсәләр.
Бу сvзләр белән килешәм, чонки 1000 елдан артык хезмәт стажлары булган педагоглар династиясенен ышанычлы дәвамчысы Наилә Рәстәм кызы Ларина.

**Наилә НАСЫРОВА**